ГЛАВА КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.4, д. Канаш,
422584

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 4 нче йорт, Канаш авылы,
422584

Тел.: (84379) 36-7-45, факс: (84379) 36-7-45.

18.10.2023 №1

# КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Канаш авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, “2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Канаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме? - «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авылы җирлегендә зиратның коймасын өлешчә киртәләү» дигән сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 66 граждан, тавыш бирүдә катнашкан 48 граждан кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- “Әйе” позициясе өчен гражданнар җыенының 48 катнашучысы тавыш бирде.
- "Юк" позициясе өчен гражданнар җыенында 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Канаш авылындагы гражданнар җыенын узган ел дип, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. “2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Канаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Канаш авылында 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме? - «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авылы

җирлегендә зиратның  коймасын өлешчә киртәләү» дигән сорау буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районының Канаш авылындагы гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Канаш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге башлыгына  җибәрергә.

Җыелышта рәислек итүче: Н.Н.Вальков